СОВЕТ НОРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«31» октябрь 2024 ел № 114

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Бюджет законнарына туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2020 елның 18 декабрендәге 17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә (22.12.2021 № 44, 29.05.2023 № 81 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 4 статьяның 6 пунктында:

- 10 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) бюджетара субсидияләрне, субвенцияләрне һәм максатчан билгеләнешкә ия бүтән бюджетара трансфертларны, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән башка субсидияләр һәм бюджет инвестицияләре алучылар тарафыннан аларны биргәндә билгеләнгән шартлар, максатлар һәм тәртипне үтәүне тәэмин итә;»;

- 11 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

- 13 пунктчада «муниципаль район» сүзләрен «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге» сүзләренә алмаштырырга;

- түбәндәге эчтәлекле 13.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«13.1) «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең интеграцияләнгән мәгълүмат системасында, капиталь кертемнәрне финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы федераль бюджет акчалары (дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) булган капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр формалаштыра;»;

1.2. 4 статьяның 7 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) бюджетара субсидияләрне, субвенцияләрне һәм максатчан билгеләнешкә ия бүтән бюджетара трансфертларны, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән башка субсидияләр һәм бюджет инвестицияләрен алучылар тарафыннан, аларны биргәндә билгеләнгән шартлар, максатлар һәм тәртипне үтәүне тәэмин итә.»;

1.3. 4 статьяның 9 пунктында:

- 6 пунктчада «бирә» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләгән көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

- 7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) бюджетка түләүләр буенча бурыч түләүгә ышанычсыз дип тану турында карар кабул итә;»;

- түбәндәге эчтәлекле 8 һәм 9 пунктлар өстәргә:

«8) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән бюджет, пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру регламентын билгели;

9) Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителә торган, бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән бүтән бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет-ресурсында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗанов